СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 1А, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 1А йорты, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Яңа Кишет авыл җирлеге Советы**

## КАРАРЫ

**« 08 » сентябрь 2026 ел**

**№21**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишетавыл җирлеге Советының “Яңа Кишет авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 24 октябрендәге 64 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 24 апрелендәге 77 номерлы үзгәрешләр белән)**

“Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Арча муниципаль районының “Яңа Кишет авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советының “Яңа Кишет авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 24 октябрендәге 64 номерлы карары белән расланган (2023 елның 24 апрелендәге 77 номерлы үзгәрешләр белән) Яңа Кишет авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Депутатның вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш муниципаль берәмлекнең тулы хокуклы составындагы вәкиллекле органының беренче утырышын уздырган көннән туктатыла.”.

2. Әлеге мәгълүматны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Кишет авыл
җирлеге башлыгы — Ф.И.Ахмадуллин